ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.03.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 698**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 06 июлендәге 1218 номерлы карары белән расланган, 2019-2023 елларга Зеленодольск муниципаль районы авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 242 номерлы карары нигезендә, 2019-2023 елларга Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны финанслау суммасын тулыландыру һәм аныклау максатында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 06 июлендәге 1218 номерлы карары белән расланган 2019-2023 елларга Зеленодольск муниципаль районы авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага (2021 елның 14 сентябрендәге 2232 номерлы карары редакциясендә) үзгәреш кертергә, ә атап әйткәндә, аны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына (http://pravo.tatartstan.ru) һәмТатарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), массакүләм мәгълүмат чаралары «Зеленодольская правда» һәм «Яшел Үзән» газеталарында бастырып чыгаруны урнаштыру юлы белән тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы — А.В.Старостин

Кушымта
Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма
комитетының карарына
кушымта

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУЕНЧА
2019-2023 ЕЛЛАРГА АВАРИЯ ХӘЛЕНДӘГЕ ТОРАК ФОНДЫННАН
ГРАЖДАННАРНЫ КҮЧЕРҮ БУЕНЧА
МУНИЦИПАЛЬ АДРЕСЛЫ ПРОГРАММА**

**Программа паспорты**

<table>
<tr><td>Программаның исеме</td><td colspan="7">2019-2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программа (алга таба - Программа)</td></tr>
<tr><td>Программаны эшләү өчен нигезләр</td><td colspan="7">«Торак фондының яшәү өчен яраксызлыгын тотрыклы киметүне тәэмин итү» федераль проектын тормышка ашыру;<br>«Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-185-ФЗ номерлы Федераль закон);<br>«2019-2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 242 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 19 июлендәге 588 номерлы карары редакциясендә)</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүче</td><td colspan="7">Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты</td></tr>
<tr><td>Программаның төп чараларын үтәүче</td><td colspan="7">Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты:</td><td colspan="7">Билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган (185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә) авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерүне финанс һәм оештыру белән тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="7">Авария хәлендә дип танылган һәм, сүтелергә һәм реконструкцияләнергә тиешле торак фондыннан гражданнарны күчерү (185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә);<br>Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен шартлар тудыру</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="7">2019-2023 еллар, шул исәптән:<br>2019 ел этабы-2020 елның 31 декабренә кадәр;<br>2020 ел этабы-2021 елның 31 декабренә кадәр;<br>2021 ел этабы-2022 елның 31 декабренә кадәр;<br>2022 елның этабы - 2023 елның 31 декабренә кадәр.<br>185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә.</td></tr>
<tr><td rowspan="3">Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="6">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2019 ел</td><td>2020 ел</td><td>2021 ел</td><td>2022 ел</td><td>2023 ел</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы</td></tr>
<tr><td>Муницип</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>64 704,00 сум</td><td>64 704,00 сум</td></tr>
</table>

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | аль бюджет | | | | | | |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - | 1 164 672,00 сум | 1 164 672,00 сум |
| | Фонд | - | - | - | - | 5 241 024,00 сумнарда | 5 241 024,00 сум |
| | Барлыгы | - | - | - | - | 6 470 400,00 сум | - |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Төп чаралар нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары программаның 1 нче кушымтасында китерелгән.<br>Программа үтәлешенең планлаштырылган күрсәткечләре Программага 5 нче кушымтада китерелгән | | | | | | |
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаны гамәлгә ашыруны гомуми контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гамәлгә ашыра;<br>Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы программаны башкаручылар белән үзара бәйләнешне, Программа чараларын тормышка ашырганда аларның эшчәнлеген координацияләүне һәм контрольдә тотуны оештыра | | | | | | |

## I. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Зеленодольск муниципаль районы дәүләт торак сәясәте мәсьәләләренең берсе-гражданнар өчен торак алу мөмкинлеген, анда яшәү өчен куркынычсыз һәм уңайлы шартлар тәэмин итә торган торак өлкәсе тотрыклы эшләвенә һәм үсешенә кучү проблемасын комплекслы хәл итүгә юнәлдерелгән, авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту хокукын тормышка ашыруны тәэмин итү.

Программада аварияле торак фонды дигәндә күпфатирлы йортларда торак урыннары җыелмасы аңлашыла, алар 2017 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән тәртиптә аларны файдалану барышында физик яктан тузу сәбәпле авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган.

2017 елның 01 гыйнварына кадәр Зеленодольск муниципаль районында 1 КФЙ авария хәлендә дип танылды, ул шәхси милектә булган 256, 8 кв.м мәйданлы 9 бинаны үз эченә ала.

Авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның күбесе билгеләнгән таләпләргә туры килә торган торак урыннарны мөстәкыйль рәвештә хәзерге вакытта сатып ала алмый.

Авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү проблемасын хәл итүгә Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетында гражданнарны күчерү өчен җитәрлек акчалар булмау каршылык тудыра.

Әлеге программа кысаларында авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү өчен Фонд һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына тиешле финанс ярдәме күрсәткәндә хәл ителергә мөмкин.

## II. Программаның төп максатлары, бурычлары һәм гамәлгә ашыру сроклары

Программаның төп максатлары булып билгеләнгән тәртиптә авария хәлендәге дип танылган авария хәлендәге КФЙлардан гражданнарны күчерүне финанс һәм оештыру тәэмин итү тора, шул ук вакытта Зеленодольск муниципаль районы федераль закон белән билгеләнгән 185-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Фонд акчалары исәбеннән финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне тәэмин итә.

2017 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән тәртиптә файдалану процессында физик яктан тузу сәбәпле авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип танылган күпфатирлы йортлар исемлеге (әлеге йортлардан гражданнарны күчерү өчен Программаны гамәлгә ашыру кысаларында финанс ярдәме күрсәтү планлаштырыла) Программаның 2 нче номерлы кушымтасында бирелгән.

Программаның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле торак фондыннан гражданнарны күчерү;
- гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен шартлар тудыру.

Программа 2019 елдан 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлгә ашырылачак.

Программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары 1 нче кушымтада китерелгән.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү чараларын гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары Фонд, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчалары исәбеннән төзелә. Программаны гамәлгә ашыруга гомуми чыгымнар барлык финанслау чыганаклары исәбеннән **6 470 400,00 сум** тәшкил итәчәк, шул исәптән акчалар:

Республика бюджетыннан - 1 164 672,00 сум;

Муниципаль бюджеттан - 64 704,00 сум;

Фондтан- 5 241 024,00 сум.

Программаны финанслау чаралары күләме Программага кертелгән, эксплуатацияләү процессында физик тузу сәбәпле, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган, күпфатирлы йортлар исемлеге, гражданнарга бирелә торган торак урыннарның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен планлаштырыла торган бәя күләме, Программага кертелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортларда гражданнар (юридик затлар) милкендә булган һәм алардан алына торган торак урыннарның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен планлаштырыла торган сатып алу бәясе күләме, шулай ук Программаның 4 нче кушымтасында каралганча, гражданнарны күчерү ысуллары белән билгеләнә.

2019-2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерүгә финанс ярдәме чараларын бүлү Программага 3 нче кушымтада китерелгән.

Сатып алу өчен бер квадрат метр бәясе Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 7нче өлеше нигезендә билгеләнә. Сатып алына торган торак өчен түләү күләме турында бәхәс барлыкка килгәндә, торак урынының базар бәясе «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында»1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законда каралган кагыйдәләр буенча билгеләнә.

Программаны гамәлгә ашырганда сатып алу бәясе якларның муниципаль берәмлек һәм авария хәлендәге торак урын милекчесе арасында төзелә торган килешүе нигезендә яисә, милекченең Программа шартлары белән килешмәгәндә, муниципаль ихтыяҗлар өчен мөлкәт суд тәртибендә тартып алынган очракта, суд карары буенча үзгәрергә мөмкин.

Авария хәлендәге торак фондының торак биналарын яллаучыларга Россия Федерациясе Торак кодексының 89 статьясына ярашлы рәвештә барлык муниципаль берәмлекләрдә торак биналар бирелә.

Фонд акчалары, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән алынган җирле бюджет акчалары түбәндәгеләргә тотыла:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән КФЙ, шулай ук торак йортларда (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган КФЙда) торак урыннар сатып алуга һәм мондый йортлар төзүгә, шул исәптән гражданнарга социаль наем шартнамәсе, яки социаль файдаланудагы торак фондының торак урынын наем шартнамәсе, яисә торак урынын наем шартнамәсе буенча торак урыннары бирү максатларында авария хәлендәге торак фондыннан күченү сәбәпле маневр фонды, яки авария хәлендәге торак фондының торак бинасы хуҗасы белән килешү буенча;

авария хәлендәге торак фондына кергән торак урыннары милекчелегендә булган гражданнарга Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 7 нче өлешенә ярашлы рәвештә алынган торак урыннары өчен түләү.

## IV. Программа чараларын гамәлгә ашыру механизмы, Программа белән идарә итүне оештыру һәм аны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту

Муниципаль заказчы программа чараларын уртак финанслауны тәэмин итү өчен Фондка заявкалар бирә, Программа башкаручылары белән планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне оештыра, Программа чараларын гамәлгә ашырганда аларның эшчәнлеген координацияли һәм тикшереп тора.

Программаны башкаручы Программа чараларын тормышка ашыру, аларның ахыргы нәтиҗәләре, бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан максатчан файдалану өчен җавап тота һәм түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүнең муниципаль программасын эшләү һәм раслауны;
- 185-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне;
- муниципаль берәмлек территориясендә авария хәлендәге торак фондына инвентаризация һәм алга таба мониторинг үткәрүне;
- гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә юнәлдерелгән чараларны тоту турындагы хисапны алып баруны һәм аны Программаның дәүләт заказчысына тапшыруны;
- гражданнарны авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле торак фондыннан социаль наем шартнамәләре яисә торак урынын милеккә тапшыру турындагы килешү буенча күчерүгә бәйле рәвештә бирүне;
- гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә юнәлдерелгән бюджет акчаларыннан файдалануны контрольдә тотуны.

Программаны гамәлгә ашыруны гомуми җитәкчелек һәм контрольдә тотуны Программаның муниципаль заказчысы гамәлгә ашыра, ул Программаны гамәлгә ашыру һәм Фондның финанс чараларын тоту барышы турында Фондка билгеләнгән срокларда хисап бирә.

Зеленодольск муниципаль районы буенча
2019-2023 елларга авария хәлендәге
торак фондыннан гражданнарны күчерү
буенча муниципаль адреслы программага
1 нче кушымта

## Зеленодольск муниципаль районы буенча 2019-2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Программаның үтәлеше күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | Программаның үтәлеше нәтиҗәсендә ирешелгән |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 4 |
| 2019-2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны үтәү нәтиҗәсендә күчерелгән халык саны | кеше | 16 |
| Программага кертелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортларда теркәлгән халыкның гомуми саныннан Программаны үтәү кысаларында күчерелгән халык өлеше | процент | 100 |
| Программаны үтәү кысаларында әлеге йортларда яшәүчеләр күчерелгән авария хәлендә дип танылган күпфатирлы йортлар саны | данә | 1 |
| Программаны үтәү кысаларында әлеге йортларда яшәүчеләр күчерелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортлар өлеше | процент | 100 |
| Программаны тормышка ашыру кысаларында торак һәм торак булмаган бүлмәләр буенча азат ителгән бүлмәләрнең гомуми саны (наем, сатып алу буенча суммада һәм алмашу буенча берәмлекләрдә һәм квадрат метрларда) | данә | Гомуми мәйданы 256, 8 кв. метр булган 9 бүлмә |
| Программаны үтәү кысаларында күчерелгән авария хәлендәге барлык күпфатирлы йортларга карата, алардан файдалану барышында физик яктан тузу сәбәпле, 2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә тиешле авария хәлендәге күпфатирлы йортларның өлеше | процент | 100 |

Зеленодольск муниципаль районы буенча 2019-2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага
2 нче кушымта

| Муниципаль берәмлек исеме | Күпфатирлы йорт адресы | Йортны файдалануга тапшыру елы | Күп фатирлы йортны авария хәлендә дип тану датасы | 2023 елның 31 декабренә кадәр авария хәлендәге торак фонды турында белешмәләр | | Күчерүне тәмамлау датасы | Күп фатирлы йортның төзелеш мәйданы, кв.метр | Авария хәлендәге күп фатирлы йорт өчен җир кишәрлеге формалаштыру турында мәгълүмат | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | мәйданы, кв. метр | кеше саны | | | җир кишәрлегенең мәйданы, кв.метр | җир кишәрлегенең кадастр номеры | җир кишәрлегенә характеристика (бер йортка формалаштырылган, формалаштырылмаган) |
| Зеленодольск муниципаль районы | Большие Ключи авылы, Волостнов ур., 2А | 1962 | 15.12.2016 | 256,80 | 16 | 31.12.2023 | 273,40 | 333,00 | 16:20:050105:117 | Бер йортка формалаштырылган |

Зеленодольск муниципаль районы буенча 2019-2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага 3 нче кушымта

**2017 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнарны авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча чараларны гамәлгә ашыруның күчерү алымнары планы**

| Муниципаль берәмлекнең исеме | Торак биналарның гомуми мәйданы барлыгы | Күчерү чараларының бәясе барлыгы | Торак урыннар сатып алуга бәйле булмаган күченү гамәлләре | | | | | Торак урыннар сатып алуга (төзүгә) бәйле гамәлләр | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | шул исәптән | | | | барлыгы | шул исәптән | | | | | сатып алынган (төзелгән) торак биналардан алга таба файдалану | | | |
| | | | | торак урыннар милекчеләренә алына торган торак урыннары өчен түләү һәм субсидияләр бирү | төзелеш территориясен үстерү һәм территорияне комплекслы үстерү турында шартнамәләр | ирекле торак фондына күченү | гражданнарга даими яшәү өчен ирекле торак фондының торак урынарын яраклы халәткә китерү | | Йортлар төзү | йорт төзүчеләрдән торак урыннар сатып алу | | йорт салучылар булмаган затлардан торак урыннар сатып алу | сатып алынган торак урыннарны гражданнарга даими яшәү өчен яраклы хәлгә | социаль наем шартнамәләре буенча бирү | социаль файдаланудагы торак фондын наем шартнамәләре буенча бирү | наем шартнамәләре буенча маневр фондының торак урынын бирү | мена килешүләре буенча бирү |
| | | | | | | | | | | төзелә торган йортларда | файдалануга тапшырылган йортларда | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | - | | - | | | - | | | - | | - | | - | | | - | | - | | - | | китеру | - | | | |
| | | | урнашу мәйданы | урнашу мәйданы | каплау бәясе | торак биналар сатып алу (тезу) өчен субсидия процентлар түләүгә | | урнашу мәйданы | устеру турындагы шартнамәләрне буенча | урнашу мәйданы | бәясе | урнашу мәйданы | сатып алына торган мәйдан | бәясе | сатып алына торган мәйдан | бәясе | сатып алына торган мәйдан | бәясе | сатып алына торган мәйдан | бәясе | сатып алына торган мәйдан | бәясе | бәясе | мәйданы | мәйданы | мәйданы | мәйданы |
| | кв.м | сум | кв.м | кв.м | сум | сум | сум | кв.м | сум | кв.м | сум | кв.м | кв.м | сум | кв.м | сум | кв.м | сум | кв.м | сум | кв.м | сум | сум | кв.м | кв.м | кв.м | кв.м |
| Зеленодольск муниципаль районы буенча барлыгы | 256,80 | 6 470 400,00 | 256,80 | 256,80 | 6 470 400,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |

Зеленодольск муниципаль районы буенча 2019-2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага
4 нче кушымта

**2017 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү чаралары планы**

| Муниципаль берәмлек исеме | Күчерергә планлаштырылган гражданнар саны, кеше | Күчерелә торган торак урыннары саны | | | Күчерелә торган торак урыннары мәйданы | | | Программаны финанслау чыганаклары | | | | Белешмә буларак: бюджет чараларын экономияләүне исәпләү суммасы | | | Белешмә буларак: торак урыннары бәясенең бер өлешен каплау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы, берәмлекләр | шул исәптән | | Барлыгы, кв.метр | шул исәптән | | барлыгы, сум | шул исәптән | | | барлыгы, сум | шул исәптән | | барлыгы сум | шул исәптән | |
| | | | Гражданнар милке, берәмлек | Муниципаль милек, берәмлек | | Гражданнар милке, кв.м | Муниципаль милек, берәмлек | | Фонд акчалары хисабына сум | Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары хисабына, сум | җирле бюджет акчалары хисабына, сум | | төзелешләрне үстерү турындагы шартнамә буенча гражданнарны күчерү хисабына сум | гражданнарның ирекле муниципаль торак фондына күченүе хисабына, сум | | торак урыннары милекчеләре акчалары хисабына, сум | башка затлар акчалары хисабына (төзелгән территорияләрне үстерү шартнамәсе буенча инвестор), |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | | | сум |
| Зеленодольск муниципаль районы буенча барлыгы | 16 | 9 | 9 | 0 | 256,80 | 256,80 | 0,00 | 6 470 400,00 | 5 241 024,00 | 1 164 672,00 | 64 704,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |

Зеленодольск муниципаль
районы буенча
2019-2023 елларга авария
хәлендәге торак фондыннан
гражданнарны күчерү буенча
муниципаль адреслы
программага
5 нче кушымта

**2017 елның 1 гыйнварына кадәр аварияле дип танылган авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерүнең планлаштырыла торган күрсәткечләр**

| Муниципаль берәмлек исеме | Урнашу мәйданы | | | | | | | | Күчерелә торган кешеләр саны, кеше | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | Барлыгы | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | Барлыгы |
| | кв.м | кв.м | кв.м | кв.м | кв.м | кв.м | кв.м | кв.м | кеше | кеше | кеше | кеше | кеше | кеше | кеше | кеше |
| Зеленодольск муниципаль районы буенча барлыгы | х | х | х | 0,00 | 256,80 | х | х | 256,80 | х | х | х | 0 | 16 | х | х | 16 |